**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

30.06.2015 ел Яр Чаллы № 2285

Биналарны, корылмаларны техник регламентларның конструктив һәм башка характеристикалар, объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документлары таләпләре нигезендә аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатында карау тәртибе турында нигезләмә

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 45 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Биналарны, корылмаларны техник регламентларның конструктив һәм башка характеристикалар, объектларның ышанычлылыгы һәм куркынычсызлыгы таләпләренә, күрсәтелгән объектларның проект документлары таләпләре нигезендә аларның техник торышын һәм тиешле техник хезмәт күрсәтүне бәяләү максатында карау тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.Х. Абзаловага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев